Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы торак пунктында үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

7 декабрь 2023 нче ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми ринциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы “Иске Кыязлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендә кабул ителгән 89 нчы номерлы “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турындагы” Карары нигезендә Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы торак пунктында 2023 нче елның 7 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде: “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эш төрләренә тотуга ризамы”

**1. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
– торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору (туфракны күтәрү, вак таш салу, вак таш сатып алу, юлларны җәен һәм кышын карап тору(кардан чистарту)-ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).
**2. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру. Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны ягулык белән тәэмин итү:**
-су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, транспортлау һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су башнялары, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (сuүткәргеч челтәренә агымдагы ремонт-торбалар, запас частьләр сатып алу, махсус техника яллау)
**3. Кабул ителгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:**
торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу,

ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

**4. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

-янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү өчен җиһазлар сатып алу, янгын сүндерү машинасын тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу

**“РИЗА” “КАРШЫ” “ТОТКАРЛАНУЧЫ”**

Җыен беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 562 кеше теркәлгән, җыенда катнашып, тавыш биргән кешеләр саны-304.

Җыенда катнашучыларның кул күтәреп тавыш бирүләре нәтиҗәсендә тавышлар түбәндәгечә билгеләнде:

“Риза” дип 304 кеше тавыш биргән
“Каршы” дип 0 кеше тавыш биргән
“Тоткарланучы” 0 кеше.

Алда китерелгән мәгълүматлар нигезендә халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы торак пунктында үткәрелгән халык җыенын уздырылган дип, җыен нәтиҗәләрен -дөрес дип исәпләргә.

Җыенда күтәрелгән түбәндәге мәсьәлә буенча чыгарылган карарны кабул итәргә: “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эш төрләренә тотуга ризамы”

**1. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

– торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору (туфракны күтәрү, вак таш салу, вак таш сатып алу, юлларны җәен һәм кышын карап тору(кардан чистарту)-ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).

**2. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру. Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны ягулык белән тәэмин итү:**

-су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, транспортлау һәм

халыкка су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су башнялары, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч челтәренә агымдагы ремонт-торбалар, запас частьләр сатып алу, махсус техника яллау)

**3. Кабул ителгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:**

торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

**4. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

1. -янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү өчен җиһазлар сатып алу, янгын сүндерү машинасын тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Карарны Татарстан Республикасының норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Дәүләтшин